ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР**
**17 мая 2019 года**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 45**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында

Җәмәгатьчелекнең дәүләт институтларына ышанычын арттыру, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи йөкләмәләрен намус белән һәм нәтиҗәле итеп башкаруга шартлар белән тәэмин итү, муниципаль хезмәттә законсыз эш йөртүне булдырмау максатыннан,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын расларга.
2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башлыгының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында” 2015 ел, 13 нче февраль, 19 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә әлеге карар белән муниципаль хезмәткәрләр таныша алуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресында урнаштырып халыкка җиткерергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы” МБ МКУ аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Р.Г. Кәлимуллин

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башлыгы карары белән
«17» мая 2019 № 45

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексы

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексы (алга таба - Кодекс) Россия Федерациясе Конституциясе, дәүләт вазыйфаи затлары үз-үзен тотышы Халыкара кодексы (БМО Генераль Ассамблеясының 1996 ел, 12 нче декабрь, 51/59 резолюциясе), Дәүләт хезмәткәрләре өчен үз-үзен тотышның модель кодексы (Европа Советы министрлар Комитеты рекомендациясенә дәүләт хезмәткәрләре өчен үз-үзен тотышы турында кодекслар, 2000 ел, 11 нче май, N R (2000) 10 нчы кушымта), “Россия Федерациясендә дәүләт хезмәте системасы турында”, “Россия Федерациясендә дәүләти гражданлык хезмәте турында”, “Ришвәтчелеккә каршы тору”, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законнар, Россия Федерациясе дәүләт хезмәткәрләре өчен чикләүләр, тыюлар һәм йөкләмәләр булган башка федераль законнар, “Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенең гомуми принципларын раслау турында”, 2002 ел, 12 нче август 885 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы һәм башка Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында”, Татарстан Республикасы Законы, ТР Президентының 2014 ел, 29 нчы ноябрь, УП-1100 номерлы Указы һәм башка Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезләмәләре нигезендә эшләп чыгарылган, шулай ук нинди вазыйфаны биләүгә карамастан муниципаль хезмәткәрләр тотарга тиешле Россия җәмәгатьчелеге һәм дәүләтенең гомум кабул ителгән әхлакый принципларына һәм нормаларына нигезләнгән.

2. Кодекс муниципаль хезмәткәрләр (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр) эш йөртергә тиешле һөнәри хезмәт этикасының һәм хезмәт урынында тәртипнең төп кагыйдәләренең гомуми принциплары җыелмасыннан гыйбарәт.

3. Муниципаль хезмәткә (алга таба – муниципаль хезмәт) эшкә керүче Россия Федерациясе гражданины Кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм аларны үзенең һөнәри эшчәнлеге процессында үтәргә тиешле, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрен кулланып.

4. Һәр муниципаль хезмәткәр Кодекс нигезләмәләрен үтәү өчен барлык кирәкле

чаралар күрергә тиеш, ә Россия Федерациясенең һәр гражданы муниципаль хезмәткәрдән Кодексның нигезләмәләре нигезендә каралган мөнәсәбәт көтәргә хокуклы.

5. Кодексның максаты – муниципаль хезмәткәрләрнең үзләренең һөнәри эшчәнлекләрен лаеклы башкару өчен этика нормаларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен ныгытуга, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм тәртип нормаларын тәэмин итү.

6. Кодекс муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз вазыйфаларын башкаруның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

7. Кодекс муниципаль хезмәт өлкәсендә тиешле әхлак формалаштыру, иҗтимагый аңда муниципаль хезмәткә карата ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру өчен нигез булып тора.

8. Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодекс нигезләмәләрен белү һәм үтәү аларның һөнәри эшчәнлеге һәм хезмәт тәртибе сыйфатын бәяләү критерийларының берсе булып тора.

## II. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе буенча гомуми принциплары һәм кагыйдәләре

1. Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе буенча төп принциплары, вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгән вакытта алар җитәкчелек итәргә тиешле үз-үзен тотышларының нигезен тәшкил итә.

2. Дәүләт, җәмгыять һәм гражданнар алдында җаваплылык тоеп, муниципаль хезмәткәрләр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

а) муниципаль органнарның нәтиҗәле эшен тәэмин итү максатларында хезмәт вазыйфаларын намус белән һәм югары һөнәри дәрәҗәдә башкарырга;

б) кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең төп мәгънәсен һәм эчтәлеген билгеләүдән чыгып эш итәргә;

в) җирле үзидарәнең тиешле органы вәкаләтләре чикләрендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

г) нинди дә булса һөнәри яки социаль төркемнәргә һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә, аерым гражданнарның, һөнәри яки социаль төркемнәр һәм оешмаларның йогынтысыннан бәйсез булырга;

д) шәхси, милек (финанс) һәм аларның вазыйфаи бурычларын намус белән үтәүгә комачаулаучы башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләрне төшереп калдырырга;

е) муниципаль хезмәткәргә карата нинди дә булса затның ришвәтчелек белән бәйле хокук бозуларга этәрү максатыннан чыгып, нинди дә булса затларның җирле үзидарә органнары хезмәткәренә мөрәҗәгать итүенең барлык очраклары турында эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиленә, прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына җиткерергә;

ж) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә, муниципаль хезмәт үтүгә бәйле бурычларны үтәргә;

з) сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр карарларының хезмәт эшчәнлегенә йогынты ясау мөмкинлеген бирми торган гаделлекне сакларга;

и) хезмәт, һөнәри этика нормаларын һәм эшлекле тәртип кагыйдәләрен үтәргә;

к) гражданнар һәм вазыйфаи затлар белән эш иткәндә иткәндә әдәплелек сакларга һәм игътибарлылык күрсәтергә;

л) Россия һәм башка дәүләтләр халыкларының гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә түземлек һәм хөрмәт күрсәтергә, төрле этник, социаль төркемнәр һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара килешүләргә ярдәм итәргә;

м) дәүләт (муниципаль) хезмәткәрләр тарафыннан вазыйфа йөкләмәләрен намуслы башкаруда шик уята алырлык үз-үзеңне тотудан тыелып торырга, шулай ук аның абруена яисә җирле үзидарә органы яисә органнарының абруена зыян китерә алырлык низаглы хәлләрне булдырмаска;

н) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм барлыкка килгән очракларны җайга салу буенча Россия Федерациясе законнары белән каралган чаралар күрергә;

о) шәхси мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен хезмәт урыныннан файдаланмаска;

п) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларына кермәгән очракта, җирле үзидарә органы, аның җитәкчеләре эшчәнлегенә карата ачык фикерләрдән, бәя бирүдән тыелып торырга;

р) җирле үзидарә органында билгеләнгән ачык чыгышлар һәм хезмәт мәгълүматы бирү кагыйдәләрен үтәргә;

с) массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең эшчәнлегенә дәүләт органы эше турында хәбәр итү, шулай ук гражданнарга һәм оешмаларга билгеләнгән тәртиптә дөрес мәгълүмат алуда булышлык күрсәтергә;

т) ачык чыгышларда, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, Россия Федерациясе территориясендә чит ил валютасында (шартлы акчалата берәмлекләрдә) бәя билгеләүдән - Россия Федерациясе резидентлары арасында килешүләр суммасыннан, Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗә бюджетлары күрсәткечләреннән, муниципаль бурыч алулар күләменнән, муниципаль бурыч күләменнән, мәгълүматларны төгәл тапшыру өчен кирәк булган очраклардан тыш, яисә Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясе халыкара килешүләре, эшлекле әйләнеш гадәтләреннән тыш, тыелып торырга;

у) аның җаваплылыгы өлкәсендә булган ресурслар белән нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итүгә һәрдаим омтылырга;

ф) үз компетенцияләре чикләрендә, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының мәдәниятен, телләрен үстерү, саклап калу; мигрантларның социаль һәм мәдәни яраклашуын тәэмин итү, төрле этник, социаль төркемнәр һәм конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга, милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, милләтара (халыкара) низагларны булдырмаска шартлар булдырырга;

х) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга бертигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый яисә дини берләшмәләргә, һөнәри яисә социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә

һәм мондый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата аерым мөнәсәбәттә булмаска;

ц) вазыйфаи бурычларны үтәгәндә расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә карамастан, кеше һәм гражданның хокукларын, ирекген һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

3.. Муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үтәргә тиешле.

4. Муниципаль хезмәткәр үз эшчәнлегендә сәяси, икътисади максатка ярашлылыгы яисә башка мотивлар буенча законнарны һәм башка норматив хокукый актларны бозуга юл куймаска тиеш.

5. Муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителгән, җирле үзидарә органында гамәлдә булган норма һәм таләпләрне тотып кына хезмәти мәгълүматны эшкәртә һәм тапшыра ала.

6. Муниципаль хезмәткәр, санкцияләнмәгән рәвештә игълан итү өчен җаваплы һәм (яки) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аларга мәгълүм булган мәгълүматның иминлеген һәм хосусыйлыгын тәэмин итү буенча тиешле чаралар күрергә тиеш.

7. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр алар өчен һөнәри үрнәк, мактауга лаек репутация үрнәге булырга, җирле үзидарә органында яисә аның бүлекчәләрендә нәтиҗәле эшләү өчен уңай мораль-психологик климат булдыруга ярдәм итәргә тиеш.

8. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр Россия Федерациясе законнары нигезендә үзенә буйсынган хезмәткәрләрнең этика принципларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен бозучы гамәлләре яки эшләмәүләре өчен җавап тота, әгәр ул мондый гамәлләрне яисә гамәл кылмауларын булдырмау чараларын күрмәсә.

## III. Муниципаль хезмәткәрләрнең ришвәткә каршы үз-үзеңне тоту стандарты

1. Муниципаль хезмәткәрләр ришвәтчелек күренешләренә каршы торырга һәм аны профилактикалау буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрергә тиеш.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганда һәм вазыйфаи бурычларын үтәгәндә муниципаль хезмәткәр аңа вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы булу мөмкинлеге турында белдерергә тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәр үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгълүмат бирергә тиеш.

4. Муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына яки башка дәүләт органнарына ришвәтчел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа нинди дә булса затлар мөрәҗәгать иткән барлык очраклар турында хәбәр итәргә тиеш.

5. Ришвәтчел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәрнамә бирү, бу фактлар буенча тикшерү үткәрелгән яки үткәрелү очракларыннан тыш, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычы булып тора.

6. Муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә физик һәм юридик затлардан (бүләкләр, акчалата бүләк, ссудалар, матди характердагы хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары һәм башка бүләкләр) бүләкләр алу тыела. Беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән алынган бүләкләр муниципаль җирле үзидарә милке дип таныла һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан акт буенча ул муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органына тапшырыла, Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән очраклардан кала.

7. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

а) башка түләүле эш башкару турында эш бирүчегә алдан хәбәр итәргә тиеш;

б) эшкә алучыдан язма рәвештә рөхсәт алырга тиеш:

- чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнүгә, әгәр дә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса;

- чит дәүләтләренең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрне, мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәннидән кала) кабул итүгә, әгәр дә муниципаль хезмәткәр вазыйфаларына күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү кертелгән булса;

в) дәүләт хезмәткәре карамагында булган кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (склад) капиталларында катнашу өлешен, пайларны) Россия Федерациясе законнары нигезендә ышанычлы идарәгә тапшырырга, әгәр дә алар милек мәнфәгатьләр каршылыгына китересәләр;

г) матди-техник һәм башка тәэмин ителеш чараларын, башка дәүләт милкен бары тик вазыйфаи бурычларны башкару белән бәйле рәвештә генә файдаланырга.

8. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәрләр түбәндәгеләрне үтәргә тиешле:

а) үз кул астындагыларның мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрергә;

б) үз кулы астында булучылар арасында ришвәтне кисәтү буенча чаралар күрергә;

в) муниципаль хезмәткәрләрне сәяси партияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр

эшчәнлегендә катнашырга мәҗбүр итү очракларына юл куймаска.

9. Башка муниципаль хезмәткәрләргә карата оештыру-боеру вәкаләтләре бирелгән муниципаль хезмәткәр үзенең шәхси тәртибе белән намуслылык, гаделлек үрнәге күрсәтергә тиеш.

10. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр арасында якын туганлык мөнәсәбәтләре һәм башка билгеләр (ата-аналаре, ире-хатыны, балалары, ир бертуганнары, кыз бертуганнары, шулай ук ире-хатынының ир бертуганнары, кыз бертуганнары, ата-аналары, балалары һәм балаларның ир-хатыннары) булып, әлеге вазыйфаи затка турыдан-туры буйсынуда яки карамагында булсалар, аларның берсе муниципаль хезмәттән азат итү яки муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү юлы белән муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасыннан баш тартырга тиеш.

## IV. Муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт этикасының гомуми кагыйдәләре

1. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт урынында кеше, аның хокуклары һәм ирекләре иң югары хәзинә булып торуы һәм һәр гражданин шәхси тормышның кагылгысызлыгына, шәхси һәм гаилә серенә, намусын, абруен, үзенең намуслы исемен яклауга хокуклы дигән конституциячел нигезләмәләрдән чыгып эш итәргә тиешле.

2. Муниципаль хезмәткәр эштә үз-үзен тотышында түбәндәгеләрдән тыелырга тиеш:

а) җенес, яшь, раса, милләт, тел, гражданлык, социаль, милек яки гаилә хәле, сәяси яки дини өстенлек бирү билгеләре буенча дискриминацион характердагы теләсә кайсы төрдәге сүзләр һәм гамәлләрдән;

б) дорфалык, кимсетү тонын күрсәтү, тәкәбберлек, ялгыш, хокуксыз, нахак гаепләүләрдән;

в) нормаль аралашуга комачаулый торган яки хокукка каршы тәртипне китереп чыгаручы янаулардан, мыскыл итә торган реплика һәм сүзләрдән, гамәлләрдән;

г) хезмәт киңәшмәләре, әңгәмәләр, граждannar белән башка хезмәт аралашуы вакытында тәмәке тартудан.

3. Муниципаль хезмәткәрләр коллективта эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруга һәм бер-берсе белән конструктив хезмәттәшлек урнаштыруга ярдәм итәргә тиеш.

4. Муниципаль хезмәткәрләр әдәпле, игелекле, төгәл, игътибарлы булырга, гражданнар һәм хезмәттәшләре белән аралашуда толерантлык күрсәтергә тиеш.

5. Муниципаль хезмәткәргә тикшерү уздырган вакытта тикшерелә торган оешманың җитәкчесе һәм хезмәткәрләре белән аны уңайсыз хәлгә куя торган яки аның ирекле һәм объектив эш итүенә тәэсир итәргә мөмкин булган мөнәсәбәтләргә кермәскә киңәш ителә.

6. Муниципаль хезмәткәр үзенең рәсми статусын өченче затларга карата кулланырга тиеш түгел.

7. Үз вазыйфаларын башкарганда муниципаль хезмәткәрнең тышкы кыяфәте хезмәт шартлары һәм хезмәт чарасы форматына бәйле рәвештә, гражданнарның җирле үзидарә органнарына ихтирамлы мөнәсәбәтенә ярдәм итәргә, рәсми,

тыйнаклык, традиционлык, пөхтәлек белән аерылып торган гомум кабул ителгән эшлекле стильгә туры килергә тиеш.

8. Муниципаль хезмәткәрнең тышкы кыяфәтенә гомуми таләпләр.

Муниципаль хезмәткәрнең тышкы кыяфәтенә булган таләпләр эш урынында, шулай ук рәсми мәсьәләләрне чишкән вакытта аннан читтә дә истә тотылырга тиеш.

Киемгә карата төп таләпләр булып чисталык, җайлылык, гадилек, зәвыклылык, уңайлылык һәм экстравагант булмау тора.

Төсләр ягыннан классик эшлекле стильгә туры килергә, зур итеп сурәтләнгән кешеләр, хайваннар һәм язулар булган кычкырып торучы принтлар булмаска тиеш.

Рөхсәт ителми:

- спорт һәм пляж стилендә булган кием-салым һәм аяк киеме, шул исәптән, шортылар, шлепанцылар;
- декоратив әйберләр кирәгеннән артык кулланылган экстравагант кием (ялтыравыклар, ташлар һ.б.), үтә күренмәле материаллардан киемнәр, кендек өлешен ачып тора торган киемнәр;
- җыйнак булмаган, үтәкләнмәгән һәм шапшак кием;
- тәннең ачык өлешләрендә пирсинг һәм татуировкалар булу;
- гадәти булмаган төсләр белән экстравагант прическалар, шулай ук панк һәм рок мәдәнияты элементлары булган прическалар.

Көзге-кышкы чорда икенче аяк киеме куллану киңәш ителә.

Хезмәт йөкләмәләрен ял һәм бәйрәм көннәрендә үтәгән вакытта көндәлек кия торган ирекле тегелешле ачыграк төстәге киемнәрне кию мөмкин.

9. Ир-атларның тышкы кыяфәтенә таләпләр.

Күлмәк һәм галстук белән классик тегелешле эшлекле костюм өстенлекле.

Эшлекле костюмга галстук сайлаганда гомуми принциплар таянырга киңәш ителә.

Җәй көне костюмсыз һәм галстуксыз кыска җиңле күлмәкләр киярргә мөмкин.

Елның салкын ел фасылларында тукылган күлмәкләр урынына эшлекле трикотаж: юка водолазка, джемперлар һ.б. кулланырга мөмкин.

Аяк киеме сайлаганда ябык классик модельле, ачык төсле булмаганнарына өстенлек бирергә.

Ир-ат һәрвакытта да чиста итеп кырынган булырга яки пөхтә итеп кистерелгән мыек, сакалдан йөрергә тиеш.

10. Хатын-кызларның тышкы кыяфәтенә таләпләр.

Өстенлекле: эшлекле костюм (чалбарлы булырга мөмкин), блузка, итәк яки классик тегелешле чалбар яисә эшлекле күлмәк.

Кыска итәк һәм күлмәкләр (ботның яртысыннан да өстәрәк булган озынлыктагы), югары киселешле (итәкнең 1/3 өлешеннән дә югары) итәк һәм күлмәкләр ярамый.

Тирән изүле, ачык аркалы, нәзек каптырмаларда булган киемнәр тыела.

Макияжда чама хисен тотарга кирәк. Табигый төсләргә якын төсләр кулланырга киңәш ителә.

Классик, пөхтә маникюр булуы мөмкин.

Бизәнү әйберләре сайлаганда тотнаклык һәм төпле урталыкны сакларга кирәк. Аякта чылбыр йөртү тыела.

Оекбашлар һәм ефәк оекларның төсе ачык булырга тиеш түгел. Бернинди рәсем булырга, шул исәптән “сеточка” булырга тиеш түгел.

Аяк киемен сайлаганда классик модельләргә өстенлек бирергә киңәш ителә.

11. Видеоконференция режимында алып барыла торган киңәшмәләрдә булучы муниципаль хезмәткәрләр, эшлекле костюм һәм галстукларда, сүндерелгән телефоннар һәм башка элемтә чаралары белән, чара башланырга 10 минуттан да соңга калмыйча килергә тиеш. Видеоконференция вакытында рөхсәт ителми: сөйләшүләр, киңәшмә эшенә карамаган башка документларны карау, киңәшмәләр залында йөрү.

## V. Низаглы хәлләр

1. Муниципаль хезмәткәр үз вазыйфаларын башкарганда низаглы хәлләр барлыкка килүгә юл куймаска тиеш. Муниципаль хезмәткәр үзен лаеклы тотарга, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, үзенең вазыйфаи регламенты, шулай ук әлеге Кодексның нормалары нигезендә катгый рәвештә эш итәргә тиеш.

2. Муниципаль хезмәткәр низаглы хәлне булдырмый кала алмаган очракта, аңа турыдан-туры җитәкче белән низаг проблемасын хәл итү зарур.

Җитәкче турыдан-туры проблеманы хәл итә алмаса яисә үзе низаглы хәлгә җәлеп ителсә, муниципаль хезмәткәр бу хакта өстә торган җитәкчелеккә хәбәр бирергә тиеш.

## VI. Кодекс нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык

Әлеге Кодекс нигезләмәләрен бозу муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм Россия Федерациясе Президентының “Федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр турында”, 2010 ел, 1 нче июль, 821 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне саклау һәм мәнфәгатьләр конфликтларын җайга салу буенча комиссияләр турында” Татарстан Республикасы Президентының 2010 ел, 25 нче август, ПУ-569 номерлы Указы нигезендә барлыкка килә торган мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия утырышында мораль хөкем ителергә тиеш, ә федераль законнарда каралган очракларда Кодекс нигезләмәләрен бозу, гамәлдәге законнар нигезендә, муниципаль хезмәткәргә юридик җаваплылык чараларын куллануга китерә.

Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Кодексның нигезләмәләрен үтәү аттестацияләр үткәргәндә, югары вазыйфаларга билгеләү өчен кадрлар резервын формалаштырганда , шулай ук дисциплинар җәза биргәндә исәпкә алына.